РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2025 Кукмара ш. № 139

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү Кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары, «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә **карар бирәм**:

1. Кукмара муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен түбәндәгечә ераклыкта билгеләргә:

1) белем бирү оешмалары (өстәмә белем бирү оешмаларыннан, өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан тыш) карамагындагы һәм (яисә) файдалануындагы биналардан, корылмалардан, төзелмәләрдән, бүлмәләрдән –

шәһәр җирлегендә 50 метр, авыл җирлегендә 10 метр;

2) балигъ булмаганнарны укытуны гамәлгә ашыручы оешмалар карамагындагы һәм (яисә) файдалануындагы биналардан, корылмалардан, төзелмәләрдән, бүлмәләрдән – шәһәр җирлегендә 50 метр, авыл җирлегендә 10 метр;

3) оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик затлар һәм эшчәнлекнең төп (устав) төре буларак медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыручы яисә төп (устав) эшчәнлеге белән берррәттән медицина эшчәнлеген Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә гамәлгә ашыручы шәхси эшмәкәрләр карамагында һәм (яисә) файдалануында булган биналардан, корылмалардан, төзелмәләрдән, бүлмәләрдән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлек буенча медицина эшчәнлеге төрләреннән тыш – шәһәр җирлегендә 20 метр, авыл җирлегендә 10 метр;

4) күчемсез милек объектлары булган һәм хокуклар билгеләнгән тәртиптә теркәлгән спорт корылмаларыннан – шәһәр җирлегендә 100 метр, авыл җирлегендә 50 метр;

5) вокзаллардан – шәһәр җирлегендә 100 метр, авыл җирлегендә 50 метр;

6) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган югары хәвефлелек чыганаклары урнашкан урыннардан – шәһәр җирлегендә 100 метр, авыл җирлегендә 50 метр;

2. Килүчеләргә хезмәт күрсәтә торган гомуми мәйданы 50 квадрат метрдан кимрәк булган җәмәгать туклануы объектларында җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган күпфатирлы йортларга якын территорияләр чикләрен күпфатирлы йорт фасадының иң якын ноктасыннан җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтүче объектка керү урынына кадәр туры (радиус) буйлап иң кыска ара буенча 15 метр ераклыкта билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Ч.Г. Хәнәфинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең 14.02.2025
елның 139 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендәге территорияләрендә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган оешмалардан һәм (яисә) объектлардан стационар сәүдә объектларына һәм (яисә) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүче объектларга кадәр ераклыкларны билгеләүнең бердәм кагыйдәләрен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

2.1. Аерымланган территория – әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән оешмалар һәм (яисә) объектлар урнашкан бинага (төзелешкә, корылмага) якын урнашкан, чикләре киртә (ясалма объектлар) белән билгеләнгән территория.

2.2. Тротуар-җәяүлеләр хәрәкәте өчен билгеләнгән һәм машина йөрү өлешенә яисә велосипед юлына тоташкан яисә алардан газон белән аерылган юл элементы.

2.3. Җәяүлеләр юлы – җәяүлеләр хәрәкәте өчен яраклаштырып төзелгән яисә җайлаштырылган җир полосасы, яисә ясалма корылма өслеге.

2.4. Җәяүлеләр кичүе – юлның тамгалар белән билгеләнгән участогы.

2.5. Җәяүлеләр йөрү зонасы – җәяүлеләр хәрәкәте өчен билгеләнгән, башы һәм ахыры махсус тамгалар белән билгеләнгән территория.

3. алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләре түбәндәге тәртиптә метрлап араны билгеләү юлы белән билгеләнә:

3.1. Аерымланган территория булганда –аерымланган территориягә килүчеләр өчен керү урыныннан алып, стационар сәүдә объектына һәм (яисә) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтә торган объектка керүчеләр өчен керү урынына кадәр.

3.2. Аерымланган территория булмаганда – әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән оешмалар һәм (яисә) объектлар урнашкан бинага (корылмага, төзелмәгә, бүлмәгә) килүчеләр өчен керү урыныннан алып, стационар сәүдә объектына һәм (яисә) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтә торган объектка килүчеләр керү урынына кадәр.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән объектлардан янәшәдәге территорияләр чикләренә кадәр ара тротуарлар яисә җәяүлеләр юллары (алар булмаганда – юл кырыйлары, велосипед юллары, машина йөри торган юл кырыйлары буйлап), җәяүлеләр кичүләре буйлап иң кыска ара буенча үлчәнә.

Җәяүлеләр йөрү зонасы машина йөрү өлеше белән кисешкәндә, ара якындагы җәяүлеләр кичүе буенча үлчәнә. Тротуарлар, җәяүлеләр юллары, җәяүлеләр кичүләре буендагы ераклык әлеге объектларның уртасыннан (үзәк сызыгыннан) үлчәнә.

5. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән объектлар бинасында (төзелмәдә, корылмада, бүлмәдә) килүчеләр өчен бердән артык керү урыны булган очракта, янәшәдәге территорияләр чикләренә кадәр ара һәр керү урыныннан билгеләнә.

6. Янәшәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләгәндә, биналарга (корылмаларга, төзелмәләргә, бүлмәләргә) һәм аерымланган территориягә керә торган янгын сүндерү, запас һәм башка юллар исәпкә алынмый.